# КАРАР

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге составына керүче Савруш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

26.10.2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Савруш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге турында» Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 05.11.2019елгы, № 96 номерлы Савруш авыл җирлеге советы карары, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставының 35 статьясына таянып, 2023 елның 26 октябрьдагы "Сез 2024 елда Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлегенең Савруш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, мобилизацияләнгән гаиләләрдән һәм Украинада махсус операциядә катнашучы контрактчылардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы»мәсьләсе белән үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән тәзелде.

1.Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
1) Савруш авылында вак таш сатып алу һәм вак таш белән капланган юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү)
2) юлларны кышкы тоту (килешү буенча эш өчен түләү)

ӘЙЕ, ЮК.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 65 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 33 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән::
- «Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 33 кеше тавыш бирде;
"юк" позициясе өчен __0_ _ җыен катнашучысы тавыш бирде.
Бу нигездә, гражданнар җыены:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге составына керүче Савруш авылы торак пунктында гражданнар җыены узган дип танылсын, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә.
2. «2024 елда Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлегенең Савруш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Украинада махсус операциядә катнашучылар: мобилизацияләнгән һәм контрактлы гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы"
1.Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
1) Савруш авылында вак таш сатып алу һәм вак таш белән капланган юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү)
2) юлларны кыш чиста тоту (килешү буенча эш өчен түләү)

- сорауы буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Татарстан Республикасы, Аксубай районы, Иске Савруш авылы, Комсомол урамы, 20, Савруш авылы, Восстания урамы, 11 адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендларны халыкка җиткерергә һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Савруш авыл җирлеге башлыгы — А.Г.Кузьмин

СОВЕТ САВРУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ